ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 14.12.2016 г. Казань № 7-20/т

Татарстан Республикасы махсуслаштырылган тукталышына тоткарланган транспорт чарасын куйган һәм саклаган өчен түләү срокларын билгеләү турында

Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы Кодексына, Федераль монополиягә каршы хезмәтнең «Тоткарланган транспорт чараларын куйган һәм саклаган өчен тарифлар исәпләү һәм түләү срокларын билгеләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында»гы 2016 елның 15 августындагы 1145/16нчы боерыгы, Татарстан Республикасының 2012 елның 17 маендагы «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган тукталышларга урнаштырган һәм саклаган, аларны кире кайтарган, урнаштырган һәм саклаган өчен чыгымнарны каплауга түләү тәртибе турында»гы 24-ЗРТ Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июлендә 468нче Карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты Положениесе белән, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Тоткарланган транспорт чараларын Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын куя торган махсуслаштырылган тукталышларга куйган көннән алып 30 көн эчендә тоткан һәм саклаган өчен түләү бәяләрен билгеләргә
2. Әлеге карар рәсми басылган көннән алып 10 көн эчендә үз көченә кертелә.

Рәис М.Р.Зарипов